## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Шәрләрәмә авыл җирлегенең Шәрләрәмә авылы торак пунктында
2024 елда үзара салым кертү турында

**2024 елның 30 марты** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге башлыгынын 20.03.2024 ел 1 нче номерлы “«Шәрләрәмә авыл җирлеге Шәрләрәмә торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 17 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегенең Шәрләрәмә торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 17 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар жыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегенең Шәрләрәмә торак пунктында гражданнар җыены билгеләү турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегенең Шәрләрәмә авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1.«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегенең Шәрләрәмә авылы торак пунктында 2024 елда үзара салым кертү турында» 17 ноябрь 2023 елнын 2нче номерлы карарына узгәрешләр кертү турында чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

1. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Беларусь МТЗ 82.1 тракторына ГСМ сатып алу; Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен запас частьләр сатып алу);
2. Шәрләрәмә торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны кардан чистарту (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);) юлларны вак таш белән каплауны оештыру(вак таш ташу)»;

2. Әлеге карарны Шәрләрәмә авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Шәрләрәмә авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Н.Н.Хуҗина